**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г. Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2021 елның 22 декабре** **3990 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәренең, максатчан тотылырга тиешле керемнәреннән тыш, 2022 елга план күрсәткечләрен билгеләү турында.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр өлкәсен үстерү, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне арттыру максатларында, «2022 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә юнәлтелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында 2021 елның 13 декабрендәге 1212 номерлы карарына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәренең, максатчан тотылырга тиешле керемнәреннән тыш, 2022 елга план күрсәткечләрен билгеләргә, әлеге карарга кушымта нигезендә.

2. Күрсәтелгән учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрдән административ - идарәче персоналның хезмәт хакын түләүгә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының бюджет учреждениеләре тарафыннан юллана торган чыгымнар күләме, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган күрсәтелгән керемнәр күләменең 50 процентыннан арта алмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

«2021 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләменең план күрсәткечләрен билгеләү турында» 2020елның 24 декабрендәге 2980 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль

бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керем күләмнәренең 2021 елга план күрсәткечләрен һәм максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителгән күләмнәрен билгеләү турында» 2020 елның 24 декабрендәге 2980 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 декабрендәге 2200 номерлы карары.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары  А.Г. Карсаловка һәм тармак территориаль бүлекләре җитәкчеләренә йөкләргә..

Җитәкче А.А.Новиков

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районы Башкарма комитетының
2021елның____ ___номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә юнәлдерелгән чыгымнар, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, 2022 елга план күрсәткечләре**

мең сум

| № | Тармак исеме | Керемнәр күләме | Хезмәт хакына җибәреләторган чыгымнар күләме |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәгариф | 14 930,0 | 7 506,0 |
| 2. | Мәдәният | 2 670,0 | 1 818,0 |
| 3. | Яшьләр сәясәте | 7,0 | 5,0 |
| 4. | Спорт | 3 180,0 | 1 666,0 |
| Тармаклар буенча барлыгы | | 20 787,0 | 10 995,0 |